СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» декабрь 2024 ел № 125

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге Советының
2023 елның 20 декабрендәге 99 номерлы
«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2024 ел һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты»
турындагы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтеры Низамова А.А.ның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2024 ел һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджетына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 декабрендәге 99 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2024 ел һәм 2025-2026 еллар план чорына бюджеты» турындагы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджетынын 2024 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджетының керемнәренең гомуми күләме 19130,1 мең сум күләмендә; авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына, үзарасалымнан кергән акча исәбенә бюджет керемнәре күләмен арттырырга;

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 19320,1 мең сум тәшкил итә.

2. № 1, № 3, № 7, № 9 кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә».

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов